Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 96 18 декабрь 2019 ел

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Советының 2017 елның 30 октябрендәге 52 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Советының 2017 елның 30 октябрендәге 52 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән), бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм терлекчелек өчен сатып алынган (бирелгән) гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - 0,3 %

1.2. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

торак фонды һәм торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган, яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) - 0,18%;»

1.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Советының 2017 елның 30 октябрендәге 52 номерлы «Җир салымы турында» карарының 4 пунктын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әлеге карарның 1.3 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакыт узу белән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга, массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Х. Абдрахманов